"Ватаным Татарстан" газета сот

Урман – минем күңел халәтем

Урманнарга матурлык, зәвык өстәр өчен кеше ярдәме кирәк. Бу бит бик күп вакыт сорый. Гомерләрен урман үстерүгә багышлаганнар моны бик яхшы аңлый. Якташыбыз, Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Харис Гайнетдин улы Мусин – шуларның берсе. "Урман – минем күңел халәтем, йөрәк дәвам, эчәр суым, сулар һавам, – ди ул. – Кеше табигатьне сакларга, Җир-анабызның бу игелекле байлыгына үсү мөмкинлеге бирүдә булышырга тиеш". Бөҗәген, җәнлеген, кош-кортын – барысын бербөтен денья итеп күрә, аларның телен аңлый. Бер карауда агачның ничек утыртылуын, урманның ничә яшьтә булуын әйтә ала ул. "Кешеләр урманнардан яшәү көче алсын иде", – ди. Республика урман хуҗалыгы агачлыкларының экологик яктан зур әһәмияткә ия булуын фәнгә нигезләнеп дәлилли Харис Мусин. Бу чыннан да шулай. Чөнки урманнар табигатьне газ, тузан сәременнән саклый, һаваны чистарта. Укучыларның һәм ата-аналарның теләгән искә алып, мәктәбебездә яшь урманчыларның "Каенкай" түгәрәге эшләп килә. Түгәрәккә 8-10 нчы сыйныфларда укучы 15 бала йөри. Максат – укучыларга экологик белем һәм тәрбия бирү, урманчы һөнәренең серләренә төшендерү, табигатьтә үзеңне тота белү күнекмәләре булдыру, табигатькә кызыксыну уяту. Укучылар индивидуаль һәм күмәк чараларда да теләп катнашалар. Мәктәптә белгечләр белән очрашулар, тематик кичәләр, күргәзмәләр, экскурсияләр, фән атналыклары, экология айлыгы уздыруга җитди игътибар бирелә, авылны, тирә-юньне яшеләндерүдә катнашабыз.

Мәктәп яны участогында да ел әйләнәсе эшнең туктап торганы юк. Узган ел яшь урманчылар 500 төп агач утыртты. Моннан ике ел элек мәктәп янында яшь урман иде, бүген анда меңнән артык куак тирә-юньгә ямь бирә.

Алга планнар тагын да зуррак: укучыларның җәйге ялын оештыру, экологик-туристик зоналар булдыру, урманчы киемнәре тектерү, иң яхшы инша, шигырь, рәсем, декоратив сәнгать номинацияләре буенча бәйгеләр үткәрү.

Экологик культура һәм әйләнә-тирә мохитне саклау елына багышланган барлык чаралар Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы, аның директоры Ренат Насыйбуллин, Рамазан Кәбиров, түгәрәк җитәкчесе Зөлфәт Әхсанов җитәкчелегендә алып барыла.

Укучылар республика күләмендә уздырылган төрле чараларда катнашырга вакыт табалар. Мәктәбебездә һәр елны туган якка кайткан сыерчыкларны яңа ясалган матур оялар белән каршы алу гадәткә кергән. Узган ел апрель ае башында Казанда Халыкара кошларны яклау көненә багышланган бәйрәм булып узды. Безнең Югары Тегермәнлек урта мәктәбенең "Каенкай" урманчылыгы әгъзалары бу чарада бик теләп катнашты. "Кошлар көне" дип исемләнгән бәйрәм чарасы 12 сәгатьтә шәһәрнең зооботаника бакчасында башланды. Бу көнне зооботаника бакчасына керү бушлай булды, әмма бер шарт белән: һәркем бирегә үзе белән сыерчык оясы алып килергә тиеш иде. Бәйрәм барышында балалар өчен кошлар темасына багышланган викторина һәм кошлар күргәзмәсе үткәрелде. Кызыклы конкурслар тәкъдим ителде, балалар өчен уеннар аеруча мавыктыргыч булды, балалар да бик актив катнашты.

Экологик тәрбия – ул дәвамлы процесс. Бүген укучыларыбыз мәктәп янындагы агачларга кошлар өчен җимлекләр ясап элделәр, яз җитүгә аларны сыерчык оялары белән сөендererләр.

Рамазан КӘБИРОВ,
Югары Тегермәнлек
урта мәктәбе директоры.

РӘХМӘТ ИШЕТҮЕ РӘХӘТ

Февраль ахырында Вишневский урамындагы җир асты юлыннан чыккан баскычта егылып, кулымны сындырдым. Хастаханәгә җибәрделәр, операция ясадылар.

Кинәт кенә булганда, ничектер куркып каласың бит ул. Җитмәсә, хәлем дә авыр иде. Шөкер, операция уңышлы үтте. Республика клиник хастаханәсе травматология институты 1 нче травматология бүлегенең табиб-травматологы **Искәндәр Александр улы Вәлитовка** игътибарлы һәм шәфкатьле булуы өчен олы рәхмәтемне белдерәм. Форсаттан файдаланып, 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне белән котлыйм. Эшендә зур уңышлар, гаилә бәхете, нык сәламәтлек телим.

Тәскирә ХӨСӘЕНОВА.
Казан

ОЧРАШУ

Журналист һөнәре – ул кешенең яшәү рәвеше. Чөнки бу һөнәр ияләренең башы иртәме-кичме, көнме-төнме, отпускыдамы – һәрвакыт мәгълүмат туплау, аны анализлау белән мәшгуль. Лаеклы ялга чыккан ветеран журналистлар да нәкъ шундый. Инде күбесе теге яки бу вакыйгага, сәяси хәлгә, тормыш-көнкүрешкә карата фикерләре белән матбугат, радио-телевидение аша укучылары, тамашачылары белән уртаклашмаса да, һәрдаим һәр яңалыктан хәбәрдарлар. Һәр нәрсәгә карата үз фикерләре бар. Алар белән бер-берсе белән телефон аша да, эшләп чыккан коллективларында да, газета-журнал редакцияләрендә дә уртаклашып, аралашып торалар. Казанның Декабристлар урамында урнашкан республиканың Журналистлар берлеге бинасында да андый очрашулар еш булып тора.

Әле шушы көннәрдә генә биредә "Сәламәтлек мәктәбе" "дәресләре" булып узды. Республика медицина профилактикасы үзәге табибы Роза Алимова һәм Республика тире-венерология авырулары диспансерының медицина профилактикасы бүлеге мөдире Станислав Сенчугов Татарстанда медицинаның һәм киң таралыш алган авыруларны кисәтүнең торышы турында ветераннарга кызыклы һәм кирәкле мәгълүматлар җиткерделәр, сорауларга җавап бирделәр. Журналистлар берлегендә Медицина профилактикасы үзәге белгечләре мондый төр очрашуларны ай саен үткәрергә планлаштыра.

Журналистлар берлегенең ветераннар советы "Онытылмас очрашулар" клубында танылган шәхесләр, төрле кы-

нары тапшырдылар. 47 укучы ин югары нәтиҗәләрне күрсәтте. Барлык предметлар буенча уртача баллар 2017 елга караганда югарырак. Математика, география, җәмгыять белеме, физика фәннәре буенча баллар уртача республика күрсәткеченнән дә югары булды.

2018 ел дәүләт йомгаклау аттестациясе буенча барлык 11 сыйныф укучылары урта белем турында аттестат алдылар. 16 чыгарылыш сыйныф укучысы "За особые успехи в учение" медале белән бүләкләнделәр.

Укучыларның саламәтлеген саклау өлкәсендә спортны үстерү, яшьләрне, балаларны физик культура белән шөгыльләнүгә тарту алгарышлы юналешләрнең берсе булып тора. Районда "Хезмәткә һәм оборонага әзер бул!" Бөтенроссия физкультура спорт комплексының этаплап кертү чаралары уңышлы гына тормышка ашырыла. 2018 елның беренче квартал йомгаклары буенча 645 укучы ГТО нормаларын тапшыруда катнаштылар. Аларның 26 сы – алтын, 55 е көмеш, 163 е бронза значоклар алдылар.

Өстәмә белем бирү системасы укучыларны җәмгыять өчен файдалы эшчәнлеккә тартуның нәтиҗәле механизмы. Узган уку елында Ф.Әхмадиев исемендәге балалар сәнгать мәктәбенең укытучылары һәм укучылары муниципаль һәм халыкара дәрәҗәдәге 40 чарада, 30 конкурс һәм фестивальдә катнаштылар, 151 призлы урын яуладылар.

"Рапсодия", "Музыкальная капель", "Камские звездочки" коллективлары, вокалистлар һәм конферансьелар–София Нәгыймуллина, Вероника Земцова, Данил Корчагин, "Созвездие-Йолдызлык–2018" эстрада сәнгате фестиваленең супер финалында чыгыш ясадылар. "Камские звездочки"бию коллективы республика этабында да өченче урынны алды.

Балаларны саламәтләндерү-белем бирү профильле үзәгендә тәрбияләнүчеләр республика һәм Бөтенроссия дәрәҗәсендә волейбол, милли көрәш, футбол, өстәл теннисы чемпионатларында, турнирларында катнашып 38 призлы урын яуладылар. Балалар иҗат үзәге укучылары республика һәм Бөтенроссия халыкара дәрәҗәдәге конкурсларда 46 призлы урынга лаек булдылар. Аеруча судомоделистлар зур дәрәҗәгә ирештеләр. Денис Наумов Әлмәт шәһәрендә узган "Технопарк юных" Бөтенроссия фестивале кысаларындагы судомоделизм ярышларында өченче урынга чыкты.

Балаларның җәйге ялын оештыру мәгариф бүлеге эшчәнлегенең мөһим юналешләреннән берсе. Җәйге каникул чорында ялның һәм мәшгульлекнең төрле формаларына 670 бала һәм үсмер җәлеп ителде. Ямаш мәктәбе базасында "Сәйлән" лагеры оештырылды. Анда 50 бала ял итте.

Бүгенге шартларда мәгариф учреждениесе белән идарә итү җитәкчеләрдән югары һөнәри осталык таләп итә. Бүген үзләренең шәхси үрнәкләре, идарә итү ысуллары белән бердәм команда туплауга ирешкән директорларыбызны билгеләп үтәсе килә. Нәкыйф Салахиев, Рамил Фәрзетдинов, Дамир Нәбиуллин, Нияз Гарипов җитәкләгән мәктәпләр ел саен укучыларга яхшы сыйфатлы белем бирүләре белән аерылып торалар.

Укучыларга сыйфатлы белем алу, иҗади салаһларен үстерү, киләчәктә алган белемнәрен куллану өчен шартлар тудыру безнең төп бурычыбыз булып тора. Ә белем бирү методикасын камилләштерү, предметларны укытуның нәтиҗәләлеген күтәрү мәктәп һәм районның методик службасының уртак тырышлыгы белән генә тормышка ашырыла торган мәсьәләләр.

бар. Кайсыдыр укуда йомшарак, ләкин өлкәннәргә булышканда башлап йөрүче. Икенчесе бераз коллективта үзен ничек тота, сыйныфташлары белән уртак тел таба-

кеше тәрәиләнә.

ЯШЬ УРМАНЧЫЛАР ТӘРБИЯЛИБЕЗ

Укучыларның һәм ата-аналарның теләгән искә алып, мәктәбебездә яшь урманчыларның "Каенкай" түгәрәге эшләп килә.Түгәрәккә VIII-X сыйныйфларда укучы 15 бала йөри. Түгәрәкне оештыруның максаты-укучыларга экологик белем һәм тәрбия бирү,аларда экологик культура формалаштыру, урманчы һөнәре серләренә төшендерү, табигатьтә үзеңне тота белү күнекмәләре булдыру, табигатькә кызыксыну уяту.

Мәктәбебездә урманда эшләүче белгечләр белән очрашулар, тематик кичәләр,күргәзмәләр,экскурсиялар,фән атналыклары, экология айлыгы уздыруга җитди игътибар бирелә, "Каенкай" түгәрәге әгъзалары авылыбызны,тирә-юньне яшелләндерүдә бик теләп катнаша.Мәктәп яны бакчасында да эшнең туктап торганы юк. Яшь урманчыларыбыз узган ел 500 төп агач утыртты.

Алдагы планнар тагын да зуррак.Төбәгебездә экологик-туристик зоналар булдыру,яшь урманчыларыбыз өчен махсус урманчы киемнәре тектерү,иң яхшы инша,шигырь,рәсем,декоратив сәнгать номинацияләре буенча бәйгеләр үткәрү-шулардан иң мөһимнәре.

Узган уку елында мәктәбебезнең X сыйныф укучылар ыКүкмара районындагы Лубян урман хуҗалыгы көллиятенә булган сәяхәттән матур тәэсирләр белән кайтты. Бу сәфәрдән без киләчәктә әлеге көллият белән ике яклы элемтәләрне тагын да ныгытырга кирәк икән дигән ныклы ышаныч белән кайттык.

Укучыларыбыз республика күләмендә уздырылган төрле чараларда да катнашырга вакыт таба.Мәктәбебездә җылы яктан кайткан сыерчыкларны ел да яңа ясалган матур оялар белән каршы алу гадәткә кергән.Быел апрель башында Казанда кошларны Халыкара яклау көненә багышланган бәйрәм булып узды. Мәктәбебезнең "Каенкай" урманчылыгы әгъзаләре бу чарада бик теләп катнашты. Әлеге бәйге балалар арасында иң яхшы мәгълүмат стенды, иң яхшы сыерчык оясы, иң яхшы иҗади эш номинацияләрендә узды. Балык Бистәсе районы исеменнән чыгыш ясаган Югары Тегермәнлек урта мәктәбе укучылары барлык номинацияләрдә дә беренче урынга лаек булды. Безгә I дәрәҗә Диплом,Татарстан Республикасының Кызыл китабы,кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

Ел башында мәктәбебездә төрле яшьтәге укучылар арасында "Шауласыннар яшел урманнар!" дигән иҗади бәйге игълан ителгән иде. Һәрбер укучы бәйге шартлары белән таныштырылды. Шунысы куанычлы, укучыларда күп төрле жанрда, төрле эчтәлектәге иҗади эшләр кабул ителде.

Нәтиҗәләр узган уку елы ахырында "Соңгы кыңгырау" бәйрәмендә ясалды. Анда иң яхшы инша, шигырь, рәсем, декоратив сәнгать әсәре билгеләнде. 21 укучы һәм 3 укытучы акчалата бүләкләр һәм Дипломнар белән бүләкләнде.

Һәр квартал саен мәктәп яны урманчылыгының "Каенкай" газетасы чыгарыла. Ул район күләмендә уздырылган мәктәп газеталары конкурсында III урынны алды, район мәгариф бүлегенең Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Узган уку елында ата-аналар һәм укучылар 105 сыерчык оясы ясады, шуларның 10 сы Казанның зооботаника бакчасына бүләк ителде. Югары Тегермәнлек мәктәбе янәшәсендә урман паркына нигез салынды, анда 15 төрдән артык агач һәм куак утырдылды.Шулай ук укучыларыбыз, "Үз агачыңны утырт" акциясендә катнашып, 300 агач утыртты.

Шунысы сөендерә: тынгысыз хезмәтебезнең инде күркәм нәтиҗәләре дә бар. Быел,мәсәлән, мәктәбебезнең 3 укучысы Казан дәүләт аграр университетының "Урман эше һәм экология" факультетына укырга керде, ә ике укучыбыз кулларына диплом алдылар. Быел исә,мәктәпнең 9 нчы сыйныфын тәмамлаган ике укучы Лубян урман хуҗалыгы көллиятендә укуларын дәвам итеп, урта белем һәм урманчы һөнәре алырга ниятлиләр.

Күптән түгел генә Күкмара районында мәктәп яны урманчылыкларының икенче республика слёты булып узды.Район данын нәкъ менә Югары Тегермәнлек урта мәктәбе яшь урманчылары яклады һәм матур нәтиҗәләр белән шатландырды.

Табигатьне саклау - үзебезне, киләчәгебезне, өебезне саклау дигән сүз. Безгә аны югалтмыйча, тагын да баетып, килер буыннарга яхшырак итү бурычы йөкләнгән.

Рамазан КӘБИРОВ,
Югары Тегермәнлек урта мәктәбе урманчылыгы җитәкчесе.